# Аннотация к рабочей Программе воспитателя по обучению татарскому языку

“Татарстан Республикасы халыклары телләре турында” Татарстан Республикасы Законында һәм татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасында мәктәпкәчә белем бирү өчен кирәкле шартлар булдыру каралган. Татарстан Республикасы Мнистрлар Кабинеты карары нигезендә кабул ителгән 2010 – 2015 елларда мәгарифне үстерү стратегиясендә (30.12.2010, № 1174) мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү учреждениеләре өчен рус һәм башка милләт балаларын татарча өйрәтү программасы, укыту-методик комплектлары (УМК) төзү бурычы куелды.

Балалар бакчасында рус балаларына татар теле өйрәтү программасы (алга таба программа) “Мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программасы структурасына федераль дәүләт таләпләре”нә нигезләнеп төзелде.

Программа 4 яшьтән 7 яшькә кадәр булган рус телле балаларны татарча аралашырга өйрәтү эшчәнлекләрен үз эченә ала. Программа мәктәпкәчә яшьтәге баланың үсеш закончалыкларына, шәхси һәм эшлекле якын килү турындагы фундаменталь тикшеренүләргә, тел өйрәтү процессында методик стандарт итеп кабул ителгән коммуникатив технология принципларына, гамәли эшкәртмәләр һәм методик киңәшлрәгә, мәктәпкәчә мәгариф системасы эшәнлеген ачыклый торган норматив-хокукый актлар, документларга нигезләнә.

**Программа принциплары**

*Коммуникативлык принцибы* балаларны татар телен аралашу чарасы буларак куллануга әзерли. Телне фән буларак түгел, ә аралашу чарасы буларак өйрәтә.

*Тел өйрәтү, тәрбия һәм үстерү бурычларының бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә тормышка ашырылу принцибы.*

*Дәвамчанлык принцибы* балалар бакчасы һәм башлангыч мәктәптә эзлеклелекне күздә тота.

*Белем бирү эшчәнлегенең мотивлашкан булу принцибы* – бала материалны үзе өчен кызык булганда үзенең шәхси ихтыяҗларына туры килгәндә генә кабул итә һәм фикерли башлавында. Тел өйрәтү процессында әкияти сюжетлар карау, кызыклы таныш геройлар белән очрашу, уен элементларын куллану тел материалын өйрәнүнең мотивлашкан булуын тәэмин итә.

*Индивидуальләштерү принцибы тел* өйрәткәндә социаль шәхес сыйфатларын үстерүне күздә тота. Балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә ала.

*Күрсәтмәлелек принцибы* тел өйрәтүне, көндәлек тормыштагы һәртөрле эшчәнлеккә бәйле рәвештә, балаларның тирә-юньне танып белүендә төп чара булып торган уен аша үткәрә.

*Интеграция принцибы* – һәр сөйләм төренең үзенчәлеген исәпкә алып алу, тәрбияче сөйләмен техник чаралар ярдәмендә тыңлау, тел үзенчәлекләрен төрле күнегүләрдә бирү, балалар ның диалогик сөйләмен үстерү.